| ГЛАВА МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2019 г. Мәлки авылы № 2

Кайбыч муниципаль районы
Кыр Буасы авылы Мәлки авыл җирлегендә
үзара салым акчаларын кертү
һәм файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2019 елның 24 октябрендә Кыр Буасы авылы , Центральная ур., 51 адресы буенча авыл клуб бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кыр Буасы авылы Мәлки авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. 2019 елның 25 октябрендә Кыр Буасы авылы, Центральная ур., 51 адресы буенча авыл клуб бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кыр Буасы авылы Мәлки авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

“Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән акчалар белән килешәсезме:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

4. Әлеге карарны Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Җитәкчесе Ф.П.Поляков